**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**№ 143**

**«21» сентябрь 2018 ел**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге составына кергән торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **И.Р. Вәлиев**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Бигеш авыл җирлеге
Советының 2018 елның
21 сентябрендәге 143 номерлы
карарына кушымта.

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге составына кергән торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге составына кергән торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында әлеге нигезләмә (алга таба – нигезләмә) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Уставы нигезендә эшләнгән.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Гражданнар җыены гомуми, тигез һәм турыдан-туры ихтыяр белдерү нигезендә үткәрелә.
1.2. Гражданнар җыенында торак пункт территориясендә даими яшәүче, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган кешеләр катнашырга хокуклы.
1.3. Гражданнар җыенында катнашу ихтыяри һәм ирекле.
1.4. Гражданнар җыенда шәхсән катнаша һәм аларның һәркайсы бер тавышка ия.
1.5. Гражданнар җыены халык тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне турыдан-туры хәл итү максатыннан үткәрелә.

## Гражданнар җыенының вәкаләтләре

1.6. Гражданнар җыены түбәндәге мәсьәләләр буенча үткәрелергә мөмкин:

торак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертүне үз эченә алган күрсәтелгән торак пункт кергән җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча;

муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы вәкаләтләре гражданнар җыены белән гамәлгә ашырыла торган җирлектә күрсәтелгән җирлекнең чикләрен үзгәртү, җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча;

муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы вәкаләтләре гражданнар җыены белән гамәлгә ашырыла торган җирлектә сайлау хокукына ия булган җирлектә

яшәүчеләр саны 100 дән артмаганда, җирлекнең вәкаләтле органын оештыру, аның саны һәм вәкаләтләр срогы турындагы мәсьәлә буенча;

муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы вәкаләтләре гражданнар җыены белән гамәлгә ашырыла торган җирлектә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча;

җирлек составына керүче торак пунктта, шәһәр эчендәге район, федераль әһәмияттәге шәһәр эчендәге территориядә, шәһәр округы яисә муниципаль район чикләрендә авылара территориядә урнашкан торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

җирлекара территориядә урнашкан торак пунктта, җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча халык инициативасын тәкъдим итү максатларында;

халык саны аз булган яки керү кыен булган җирдә урнашкан җирлектә, әгәр авыл җирлегендә халык саны 100 кешедән артмаса, җирлекне бетерү мәсьәләсе буенча;

авыл торак пунктында авыл җирлеге старостасы кандидатурасын тәкъдим итү, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс үткәргәндә, конкурс комиссиясе составына кандидатуралар күрсәтү максатларында үткәрелергә мөмкин.

**Халык җыенын матди һәм оештыру ягыннан тәэмин итү**

1.7. Җыен муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

1.8. Җыенга әзерлек һәм аны үткәрү белән бәйле чыгымнар муниципаль берәмлек бюджеты хисабына башкарыла.

## 2. Халык җыенын чакыру тәртибе

Халык җыенын үткәрү инициативасы

2.1. Торак пунктта гражданнар җыенын үткәрү инициативасы түбәндәгеләрнеке була ала:

- муниципаль берәмлек башлыгыныкы;
- торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия халык җыенында катнашу хокукы булган 10 кешедән дә ким булмаган төркеменеке (ягъни Россия Федерациясенең үз гамәлләре өчен җавап бирүче даими яки күбесенчә торак пункт территориясендә яшәүче, яшәү урыны буенча бу торак пунктта теркәлгән, 18 яшькә җиткән гражданнары, шулай ук торак пункт территориясендә даими яисә күбесенчә яшәүче һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашырганда Россия Федерациясенең халыкара килешүләре һәмфедераль законнар нигезендә хокукка ия булган чит ил гражданнары).

2.2. Торак пунктта яшәүчеләрнең инициативасы имза куелган битләр (1 нче кушымта) яки халык җыенын үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында карар

кабул ителгән инициатив төркем җыелышының беркетмәсе рәвешендә рәсмиләштерелергә, аларда түбәндәгеләр күрсәтелгән булырга тиеш:

халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләләр;

халык җыенын үткәрүнең тәкъдим ителгән вакыты;

халык җыенын чакыру турындагы инициативаны хуплаучы һәр гражданинның паспорт сериясе һәм номеры, яшәү урыны, аның имзасы һәм имзасын теркәү датасы.

2.3. Җыенны үткәрү инициативасын хуплау өчен җыелырга тиешле имзалар саны сайлау хокукына ия булган, даими яки күпчелек вакытта шунда яшәүче, торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар саныннан 5 процент тәшкил итәргә тиеш, ләкин имзалар саны 10 нан да ким була алмый.

2.4. Кул куелган кәгазьләр имзалар җыючы зат тарафыннан, таныклау датасын, фамилиясен, атасының исемен, туган датасын, паспорт номерын һәм сериясен, яшәү урынын күрсәтеп, таныклана һәм муниципаль берәмлек башлыгына җибәрелә.

Халык җыенын үткәрү турында карар кабул итү тәртибе

2.5. Инициатив төркем тарафыннан чакырыла торган халык җыены муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән (2 нче кушымта), ә муниципаль берәмлек башлыгы инициативасы белән җыела торганы – муниципаль берәмлек башлыгы карары белән (3 нче кушымта) барлык кирәкле документлар кергәннән соң 30 көн эчендә билгеләнә.

2.6. Муниципаль берәмлек башлыгы яисә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы, аның максатка ярашлы булмавы сәбәпле, халык җыенын үткәрүдән баш тартырга хокуклы түгел.

2.7. Халык җыенына (халык җыены этапларына) чыгарылган мәсьәлә Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәскә тиеш. Халык җыенына чыгарылган мәсьәлә аны күптөрле аңлау мөмкинлеген булдырмау максатыннан чыгып формалаштырылган булырга тиеш, ягъни аңа бары тик бертөсле җавап кына бирергә мөмкин булырлык итеп формалаштырылган булырга тиеш.

2.8. Халык җыенын билгеләү, аны күчерү турында карарны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибе муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә һәм муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен муниципаль берәмлек уставында каралган тәртиптә басылып чыга (халыкка җиткерелә).

Халык җыенын үткәрү турында муниципаль берәмлек башлыгы яисә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарында түбәндәгеләр күрсәтелә:

халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләләр;

халык җыенын уздыру вакыты һәм урыны турында мәгълүмат;

җыенны оештыручы - муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсе турында мәгълүмат.

2.9. Халык җыенын әзерләү һәм уздыру өчен җаваплы муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсе (башкарма-боеру органы), муниципаль берәмлек башлыгы яки муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары нигезендә сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләр исемлеген төзи;

халык җыенына мәгълүмати материаллар әзерли;

муниципаль берәмлек халкына халык җыены турында массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән хәбәр итә (4 нче кушымта).

Муниципаль берәмлекнең башкарма-боеру органы халык җыенын үткәрү өчен бина бирергә тиеш.

2.9.1. Торак пунктта яшәүчеләргә гражданнар җыенының вакыты һәм урыны турында алдан ук хәбәр ителә. Гражданнар җыенын билгеләү турында карар, гражданнар җыенын уздыру вакыты һәм урыны гражданнар җыенын уздыру датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

2.9.2. Гражданнар җыенының һәр катнашучысы гражданнар җыенын үткәрү датасына кадәр 5 көн алдан муниципаль берәмлек органы структур бүлекчәсендә әлеге нигезләмәнең 2.9 пунктында күрсәтелгән гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышырга, шулай ук аларның күчермәләрен алырга хокуклы.

2.10. Гражданнар җыены турында нигезләмә нигезендә гражданнар җыенын уздыру датасы соңрак вакытка күчерелергә мөмкин. Гражданнар җыенын күчерү турында карар җыенны уздыру билгеләнгән датага кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

## 3. Халык җыенын үткәрү тәртибе

3.1. Җыенга килгән гражданнар торак пунктта яшәүчеләр исемлегенә кертелгән һәм сайлау хокукына ия булган затларны теркәү өчен муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләт биргән зат тарафыннан теркәлә. Исемлектә кешенең фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны, паспорт сериясе һәм номеры күрсәтелә.

3.2. Җыенга шулай ук катнашырга теләк белдергән хәлиткеч тавыш бирү хокукы булмаган башка гражданнар, җыенда тикшерелә торган мәсьәләләрне хәл итү эшчәнлекләренә кагыла торган предприятие,учреждение, оешма җитәкчеләре, матбугат һәм башка массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре кертелә.

3.3. Сайлау хокукына ия торак пунктта яшәүчеләр исемлегендә төгәлсезлекләр ачыкланган очракта, торак пунктта яшәүче кеше әлеге муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан теркәлергә һәм җыенга кертелергә мөмкин.

3.4. Язмаларның төгәлсезлеген (яисә аларның юклыгын) раслау өчен гражданның шәхесен раслый торган документ булу хезмәт итәргә мөмкин (Россия Федерациясе гражданы паспорты, хәрби билет, чит ил гражданы паспорты, Россия Федерациясендә тору өчен кәгазь, Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүгә рөхсәт һәм башкалар).

3.5. Халык җыены анда сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы катнашканда хокуклы санала. Кворум булмаганда, халык җыенын үткәрүнең яңа датасын билгеләү муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан башкарыла. Бу очракта халык җыены халык җыенын үткәрү көне билгеләнгәннән соң ун көннән дә соңга калмыйча үткәрелергә тиеш.

3.6. Халык җыенында тавыш бирү ачык яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин.

Тавыш бирү формасы турында карар халык җыены тарафыннан кабул ителә (вариант буларак: форма халык җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә белән билгеләнә).

3.7. Яшерен тавыш бирүне уздырганда халык җыенында катнашу өчен теркәлгән кешегә тавыш бирү өчен бюллетень (5 нче кушымта) бирелә.

3.8. Халык җыенында муниципаль берәмлек башлыгы яисә халык җыенында теркәлгән катнашучылар саныннан гади күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән сайланган башка зат рәислек итә ала. Рәислек итүгә кандидатларны халык җыенында катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы.

3.9. Гражданнар җыены секретарьны һәм хисап комиссиясен сайлый. Хисап комиссиясе әгъзаларының саны ике кешедән дә ким була алмый. Өстәмә сораулар гражданнар җыенының көн тәртибенә рәислек итүче, муниципаль берәмлек башлыгы, гражданнар җыенында катнашу хокукы булган гражданнар тарафыннан кертелергә мөмкин. Көн тәртибенә гражданнар җыены инициаторлары керткән мәсьәләләр берсүзсез кертелә. Күрсәтелгән мәсьәләләр беренче чиратта карала. Өстәмә мәсьәләләрне гражданнар җыенының көн тәртибенә кертү турындагы карар, әгәр аның өчен җыенда катнашкан гражданнарның кимендә яртысы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

3.10. Гражданнар җыены рәислек итүче тарафыннан ачыла. Гражданнар җыенында рәислек итүче гражданнар җыенын үткәрүне оештыра, тәртипне саклый, хисап комиссиясе эшен координацияли, фикер алышына торган мәсьәләләр буенча чыгыш ясау өчен сүз бирә, тавыш бирүнең билгеләнгән тәртибен тәэмин итә.

3.11. Халык җыенында сәркәтип тарафыннан халык җыенын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны, торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны, көн тәртибе, чыгышларның кыскача эчтәлеге, карала торган мәсьәләләр буенча тавыш биргән гражданнар саны күрсәтелгән беркетмә алып барыла (6 нчы кушымта).

3.12. Беркетмәгә җыенда рәислек итүче зат, җыен сәркатибе кул куя һәм ул муниципаль берәмлек башлыгына тапшырыла. Беркетмәгә җыенда теркәлгән катнашучылар исемлеге теркәлә.

## 4. Гражданнар җыены карарлары

4.1. Халык җыены карары сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш биргәндә кабул ителгән дип санала.

4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып тора, муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш. (7, 8 нче кушымталар).

4.3. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары, җирлек уставы белән билгеләнгән вәкаләтләр бүленеше нигезендә, халык җыенында кабул ителгән карарларның үтәлешен тәэмин итәләр.

4.4. Җыенда кабул ителгән карар җыенда башка карар кабул итү юлы белән юкка чыгарылырга, үзгәртелергә яки суд тәртибендә гамәлдә түгел дип танылырга мөмкин.

4.5. Халык җыенында кабул ителгән карарлар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) һәм муниципаль хокукый актлар таләпләре нигезендә рәсмиләштерелергә тиеш.

4.6. Әгәр торак пунктта яшәүчеләрнең туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә муниципаль хокукый акт кабул итү (әзерләү) кирәк булса, күрсәтелгән актны кабул итү (әзерләү) компетенциясенә керә торган җирле үзидарә органы яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи заты халык җыенында кабул ителгән карар үз көченә кергәннән соң 15 көн эчендә тиешле муниципаль хокукый актны әзерләү һәм (яисә) кабул итү вакытын билгеләргә бурычлы. Әлеге вакыт өч айдан артмаска тиеш.

## Гражданнар җыены карарларын үтәү

4.7. Җыенда кабул ителгән карарлар торак пункт территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш һәм нинди дә булса дәүләт хакимияте органнары, аларның вазыйфаи затлары яисә җирле үзидарә органнары тарафыннан раслауга мохтаҗ түгел.

4.8. Җыенда кабул ителгән карарлар үтәлмәгәндә закон нигезендә җаваплылык каралган.

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районының
Бигешавыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

### ИМЗАЛАР КӘГАЗЕ

Без, имзалар кәгазенә кул куючылар, түбәндә күрсәтелгән вакытта куелган мәсьәлә буенча үткәреләчәк ____________________________________________
(гражданнар җыенын уздыру сроклары)

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигешавыл җирлегенең_________ торак пунктында гражданнар җыенын уздыру инициативасын хуплыйбыз.
____________________________________________
____________________________________________

| №№ п/п | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туган елы | Яшәү урыны адресы | Паспортның, аны алмаштырган документның сериясе, номеры | Имзаның датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Имзалар кәгазен таныклыйм___________________________________________________
(Имзалар җыючының фамилиясе, исеме, атасының исеме,

___________________________________________________________________________
туган елы, яшәү урыны, паспортының, аны алмаштыручы документның сериясе, номеры)

___________________ (имза һәм дата)

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районының
Бигешавыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Совет Сармаш-Башского сельского поселения Заинского муниципального района**
423532 с.Сармаш-Баш, ул.Центральная, дом 114 телефон 88555839030

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Зәй муниципаль районы Бигешавыл җирлеге (шәһәр округы) Советы**
423532 Бигешавылы, Үзәк ур. 114 йорт
телефон88555839030

ОГРН_______ , ОКПО______ , ОКАТО_______,
ИНН/ КПП _____/______,ОКТМО ______

## КАРАР

**_______ 20** ел** **№ ____**

**Гражданнарның үзара салым средствосын кертү һәм аны куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигешавыл җирлегенең _______________ торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56

статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Бигешавыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигешавыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигешавыл җирлегенең _ _ _ _ _ торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены 20__ елның _________ билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигешавыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан кала, 20__ елда үзара салымны _____ күләмендә билгеләргә һәм җыелган сумманы җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез ризамы:

«ӘЙЕ» «ЮК»

2. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында һәм Чыбыклы авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгәннән соң _____ көн эчендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе
авыл җирлеге башлыгы _______________

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районының
Бигешавыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә 3 нче кушымта

| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**Совет ___________ сельского поселения**<br>**Заинского муниципального района**<br>индекс с. ул. дом телефон | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**____ муниципаль районы ____авыл җирлеге (шәһәр округы) Советы**<br>индекс ___авылы ___ ур. йорт<br>телефон |
|---|---|

ОГРН_______ , ОКПО______ , ОКАТО_______,
ИНН/ КПП _____/______,ОКТМО ______

---

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигешавыл җирлеге башлыгының 20__ елның ___ _____________ ___номерлы карары**

**«Гражданнарның үзара салымын кертү һәм аны куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигешавыл җирлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигешавыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигешавыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигешавыл җирлегенең _________ торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены 20__ елның _________ билгеләргә.

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигешавыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан кала, 20__ елда үзара салымны _____ күләмендә билгеләргә һәм җыелган сумманы җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез ризамы:

« ӘЙЕ» «ЮК».

2. Карарны кабул ителгәннән соң _____ көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Зәй муниципаль районы
__________ авыл җирлеге башлыгы ____________________

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районының
Бигешавыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә 4 нче кушымта

Сайлау хокукына ия Бигешавыл җирлегендә яшәүчеләрнең
ИСЕМЛЕГЕ
«___» __________________ 20___ ел

| №№ пп | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туган елы (18 яшьтә - туган елының ае, көне) | Яшәү урыны адресы | Паспорт сериясе, номеры | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Гражданнар җыенында рәислек итүче _________ ______________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)
Гражданнар җыены секретаре _________ ______________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районының
Бигешавыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә 5 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чубыклы авыл җирлеге составына кергән ___________________ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм аны куллану мәсьәләсе буенча яшерен тавыш бирү

БЮЛЛЕТЕНЕ

| | |
|---|---|
| Яшерен тавыш бирүгә куелган мәсьәләнең эчтәлеге | «Әйе» ☐ |
| | «Юк» ☐ |
| | «Тавыш бирмим» ☐ |

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районының
Бигешавыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә 6 нчы кушымта

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ БЕРКЕТМӘСЕ

________________________________________________

«___» ____________ 20__ ел №_____

______________________________
(торак пунктның исеме)

Катнашты ______________________________________________ кеше.
(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Рәислек итүче ________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Секретарь ________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**Көн тәртибе:**
1.

2.

**Беренче мәсьәлә буенча тыңладылар:**

______________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

**Чыгыш ясады:** 1. ______________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(по количеству выступающих граждан)(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә)
һәм шул тәртиптә дәвам итә (чыгыш ясаучылар саны буенча)

**КАРАР ИТТЕЛӘР:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Әйе» - ____ кеше
«ЮК» - ____ кеше
«Тавыш бирми калдым» - ____ кеше
Карар ________________________________________
кабул ителде (кабул ителмәде)
**Икенче мәсьәлә буенча тыңладылар:**

________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

**Чыгыш ясады:** 1. ___________________________________________________
(фамилиясе, исеме, имя, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә)
һәм шул тәртиптә дәвам итә (чыгыш ясаучылар саны буенча)

**КАРАР ИТТЕ:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Әйе» - ____ кеше
«Юк» - ____ кеше
«Тавыш бирми калу» - ____ кеше

Карар__________________________
кабул ителде (кабул ителмәде)

Рәислек итүче _________ __________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)
Секретарь _________ __________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районының
Бигешавыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә 7 нче кушымта

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигешавыл җирлеге составына кергән _________________ торак пунктында гражданнар җыенын үткәрү нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигешавыл җирлегенең __________ торак пунктында үзара салым кертүгә сез ризамы дигән мәсьәлә буенча 20__ елның _______ узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә ____ кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны ____ кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында "Әйе" дип _____ катнашучы тавыш бирде; "Юк" дип җавап бирүчеләр саны ____ кеше.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигешавыл җирлегенең _____ торак пунктында гражданнар җыенын узган һәм гражданнар җыены нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигешавыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан кала, 20__ елда үзара салымны _____ күләмендә билгеләргә һәм җыелган сумманы җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез ризамы, дигән мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга: 1)…; 2)….

3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигешавыл җирлеге гражданнар җыены нәтиҗәләрен халыкка җиткерергә (гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итү ысулын күрсәтергә).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигешавыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче ________________ ________________________

(имза) (имзаның расшифровкасы)

Муниципаль берәмлек башлыгы,

Совет рәисе ________________ ________________________

(имза) (имзаның расшифровкасы)

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районының
Бигешавыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә 8 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сарма-Баш авыл җирлегенең ________________ торак пунктында узган

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«___» ___________ 20__ ел №_____

В соответствии со статьями 25.1, 56 Федерального закона «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации», статьей 35 Закона Республики Татарстан «О местном самоуправлении в Республике Татарстан»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә

Зәй муниципаль районы Бигешавыл җирлеге гражданнары җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1.
2.
3.

Рәислек итүче: __________ ____________

(имза) (имзаның расшифровкасы)

Муниципаль берәмлек башлыгы,

Совет рәисе: _________ ______________

(имза) (имзаның расшифровкасы)